# Н.ФӘТТАХ "ИТИЛ СУЫ АКА ТОРУР"

(ГЕРОЙЛАРГА ХАРАКТЕРИСТИКА, СҮЗЛЕК ЭШЕ, ӘСӘРДӘГЕ ТӨП КАРШЫЛЫКЛАР)

# СҮЗЛЕК

- АЛПАГЫТ –батыр, алып, көрәшче.
- БИ –эре хуҗа, җир-су, байлык иясе; бай кеше.
- БИКӘ –хуҗаның хатыны, танылган нәселдән булган кыз яки хатын.
- БИТЕК –язу, хат.
- БИТЕКЧЕ –язу-сызу эшләрен алып баручы.
- ЙОЛЫК –корбан чалу.
- ЙОЛЫК ТУЕ –корбан бәйрәме
- КАГАН –борынгы төркиләрдә дәүләт башлыгы, хан, патша.

- КАТАУ –коймалар белән ныгытылган, кораллы гаскәр тарафыннан саклана торган торак урын. Анда гадәттә ханнар, биләр яшәгән.
- КАЛАН –сугышта җиңелүчегә түли торган еллык салым, ясак.
- КАМ –йола-дин башлыгы.
- ОГАН –көрәшче, сугышчы.
- РУМ –християн динендәге кеше.
- СУКМАН –батыр сугышчы, алып.

- ТОТЫК –берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен дошман якларның берсе тарафыннан кулга алынган каршы як кешесе (заложник).
- ЯГЫ –дошман.
- ЯЗЫК –гаеп, ярамаган эш.
- УГЛАН –хан яисә би баласы.
- ЧУМАК –мөселман динендәге кеше.
- ЫМ –сугышчыларның очрашканда бер-берсен тану өчен алдан билгеләп куйган сүзе, пароль.
- **ҖӨФҮТ** –яһүд динендәге кеше.

# ӘЛЕГЕ ӨЗЕКТӘ СҮЗ КЕМ ТУРЫНДА БАРА?

- “Атасы кебек ул таза,эре сөякле иде . Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк. Борын асты әле анын яңа гына караеп килә”.

# ЖАВАП:

- ТОТЫШ

- “Ул үзенең үткән бала чагы белән, көн дә күреп өйрәнгән агач өйләр, тар урамнар, җилдә-яңгырда караеп беткән коймалар, капкалар белән, кырыс ирләр белән, зәңгәр түтеннәр белән саубуллашты”.

# ҖАВАП:

ТОТЫШ

- “Ул илле яшьләр чамасындагы богадай таза, имәндәй төз, озын буйлы ир иде. Тик бу тыштан караганда гына шулай. Таза”имәннең” эченә корт төшкән иде”.

- Күрән би

- “Ул чибәр, би аны башкаларга караганда да ныграк ярата. Бу аңа икеләтә көч бирә. Ул инде үзен дә, углын да юкка-барга кыерсыттырмый башлады. Киресенчә, элеккеләрнең үчен кайтарырга теләп, көндәшләрен, әкренләп-әкренләп, ул үз кулына ала барды”.

- Койтым бикә

- “Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше.”

- Ямгырчы би

- “Юлда,тар аралыкта яхшы акбүз атка атланган бер кеше күренде. Бу кеше йөзләгән, меңләгән ир-атлар арасында таудай калкып, ерактан ук күзгә ташланып тора иде.”

- Алмыш хан

- “Баштанаяк ул тимергә төренгән, шуңа күрә аның сөңге, кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юктыр кебек. Үзенең таза, көр кола атында ул таштан уеп ясалган баганадай нык утыра; киң битле, зур башлы.”

- Чәкән алпагыт

- “Ул чирмеш, урман кешесе, шуңа күрә атта яхшы орыша алмый. Аяк өсте орышка исә аңа беркем каршы тора алмый иде.”

- Будрач сукман

- “Үзенең җиңгәнлеген белдереп, кызыл итеге белән аның күкрәгенә басты, кылычын итек башы янына терәде.”

- Корыч-Тимер

# ӘСӘРДӘГЕ ТӨП КАРШЫЛЫКЛАР:

- КҮРӘН БИ
- (Ак бүре ыруы)
- АЛМАШ ХАН
- (Болгарлар ыруы)

# Сәбәбе:

Алмаш ханның этисе Шелкә үлгәч, Күрән би аңа 3 ел калан түләмәгән. Ул шуны алырга килгән.

# СӘБӘБЕ :

- Илне, Ак бүре ыруын саклап калу

# нәтиҗә:

- Тотыш өченче алып, Корыч-Тимер белән сугышканда җиңелә, шуннан соң, Алмаш хан аны үзенә тотык итеп ала.